## ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ





Наил ШӘРИФУЛЛИН

# Динсез дөнья сансыз

Иртәгә – Бөтендөнья дин көне. Кешелек тарихы ул – сугышлар тарихы гына түгел, диннәр тарихы да. Кеше заты һәрчак нәрсәгә булса да ышанган. Ышанырга мәҗбүр булган. Чөнки аны урап алган тирәлек, табигатьтәге күренешләр нинди дә булса аңлату сораган. Нинди дер югары көч, югары акыл юк икән, ул урман-кырлар, таулар, елга-диңгезләрне, күп төрле җәнлекләрне, үсемлекләрне, җимеш агачларын кем барлыкка китергән соң? Үзеннән-үзе ярала алмый ич алар. Борынгы кешенең мантыйгы, ихтимал, шундыйрак булгандыр.

Дин булмаса, бүгенге дөнья нинди рәк булыр иде икән? Ихтимал, начаррак. Диннәр йогынтысы кимеп барган хәзерге чорда да алар бик күпләр өчен маяк, начарны яхшыдан аерып күрсәтүче хөкемче, модератор ролендә кала әле. Яшерен-батырын түгел, диннәр бүгенге технологияле заманга җайлашты. Һәм бер үк вакытта элекке дәверләрдә булган көчен дә җуйды кебек. Бу күренештә тискәре һәм уңай яклар бар. Уңай як шул: көчле, йогынтылы чорларда диннәрнең роле гел генә саваплы булмаган бит.

Әлбәттә, мәҗүсилек дәверләре, мәсәлән, шул ук антик чор булган. Диңгезнең – үз алласы, җир астының – үзенеке. Әле тагын уңыш алласы, тимерчелекнеке, гаиләнеке – борынгы грек һәм римлыларның дистәләгән аллаларының һәрберсе үз юнәлеше өчен җавап тоткан. Тик нәрсәдер, кемнәрдер артык күп икән, аның кадере зурдан булмый шул инде. Классик, дөньяви диннәр тантанасы чорындагыдан аермалы буларак, шул ук греклар, аллаларга ышанса да, алардан бер дә курыкмаган. Ул гынамы, алар турында кырыкмаса-кырык төрле миф, хәтта мәзәкләр чыгарган. Кырын ятып, вино эчкән, күңел ачкан чакларда Зевс һәм аның хатыннары хакында көлешә-көлешә, кем әйтмешли, хагын да, нахагын да сипкән алар. Тыюлар бөтенләй дә күзәтелмәгән.

Төп дөньяви диннәрнең берсе булган нәсарилык, ягъни христианлык яралгач, вазгыять, әлбәттә, нык үзгәргән. Яңа дин белән дүрт гасыр буе көрәшкән Рим, ахыр килеп, аны үзенең дәүләт дине иткәч бигрәк тә. Аллаһы бары берәү. Аның тәгълиматына, ул кушканнарга бәндә сүзсез буйсынырга, ул кушканча гына яшәргә тиеш. Ягъни дин кешенең тормыш-көнкүрешенә үтә, аны регламентка сала башлый. Әлбәттә, чама белгәндә, бу гамәлдә бер начарлык та юк. Ләкин… Чама бөтенләй калмаган Урта гасырларда шул ук Европада инквизиция дип аталган чиркәү судының нинди җинаятьләргә барганы күпләргә мәгълүм. Яла аркасында сихерче келәймәсе алганнардан башлап, дин әйткәнчә яшәмәүче, хәтта уйламаучыларны, шул исәптән «Җир Кояш тирәли әйләнә» дигән инанудан баш тартмаган Джордано Бруноны чаклы, күп сөйләшеп тормастан, баганага бәйләп, утта яндырганнарын беләбез. Ә бит барысы да дин, Алла исеме белән башкарылган.

Нәсари диненнән җиде гасырга соңрак яралган исламны, аның элекке чорларын да ул яктан бөтенләй үк гөнаһсыз дип әйтеп булмый. Безнең дин очрагында да бәндәне яхшы итәргә теләп, начарга, дини диктатурага кереп киткән чорлар булмаган түгел, булган. Мөхәммәт пәйгамбәр, язуларынча, төрле рәхимсезлекне, кешене терелэй яндыру кебек коточкыч кыргыйлыкларны тыйган тәкъдирдә дә. Дөньяви диннәрнең иң өлкәне иудаизмда да, исламда да җәзаларның шактый дәһшәтлеләре – мәсәлән, иренә хыянәт иткән хатын-кызны ташлар белән сугып үтерү гадәте булганы билгеле. Цивилизация барып җитмәгән тарафларда андый вәхшилек бүген дә бар, диләр. Моның ише хәлләр – җиңелрәк җәза кулланасы урында, урлашкан өчен кулны кисү, үзара якынлык өчен ир-атларны үлемгә хөкем итү кебек үтә кырыс җәзалар динне, миңа калса, бик үк бизәми.

Дөнья, сирәк тарафларны исәпләмәгәндә, Урта гасырлардан, шөкер, чыкты. Әйткәнебезчә, заманнар белән бергә диннәр дә үзгәрде. Христиан диненең соңрак олы бер тармагы булып киткән протестантлык тумаса, Европа бүгенге Европа була алыр иде микән? Юктыр. Хезмәтне, хәләл көч белән баюны культ дәрәҗәсенә күтәргән, дини кануннарга аек акыл белән караган, күңел ачулы, исерткеч эчемлекле тормышны хупламаган шул дингә кереп киткән дәүләтләрдә бүген иң югары тормыш сыйфаты. Протестант дине үзе белән янәшә яшәгән католикларны да үзгәрткән. Тик Испания, Португалиянең, тормыш дәрәҗәсе дигәндә, күпчелек халкы протестант динендә торган Швеция белән Германияне уза алганы юк әле. Әлбәттә, бүген Европа илләрендә тоташ диндарлык күзәтелми. Тик Реформация чоры продукты булган, XVI гасырда яралган без әйткән дин, аннан соңгы өч йөз ел дәвамында – йогынтысы көчле чакта – үз эшен шәпләп башкарып чыккан, дияргә мөмкин.

Византиядә яралып, Россиягә күчкән, безнең тарафларда ислам белән янәшә яшәгән православие дә – христиан диненең бер тармагы, состав өлеше. Гәрчә католиклар белән протестантларның кайсылары аңа секта дип, өстән аска караса да. Әлеге диннең дә яши-яши үзгәрешләр кичергәнлеген, Россиядәге христиан диненә унификация керткән Никон реформаларын беләбез. Әмма реформаның төрлесе була. Үзләрен иске дин вәкилләре (старообрядцы, староверы) дип атаган, XVII гасырдан соң да элекке кыйблаларына тугры калган христианнарның, мәсәлән, хезмәткә мөкиббәнлеге, чиста-пөхтәлеге, спиртлы эчемлекләргә сак мөнәсәбәте аларны протестантларга охшаш итә. Күптән бер язганымча, ул дин вәкилләре арасында иганәчелек бик популяр булган. Шул ук Казан староверлары кылган изге эшләр, алар төзеткән биналар турында язсам, сүз озакка китәчәк. Фикеремне беркемгә дә көчләп такмыйча, шуны сорыйсым килә: Никон реформалары Россия үсешендә күпмедер кире роль уйнамады микән?

Бик күп төрки халыклар белән бергә без – татарлар да үз иткән ислам диненә кайтыйк. Башка төп диннәр белән чагыштырганда мин аны көчле һәм нәтиҗәлерәк дин дияр идем. Башка конфессия вәкилләре кими барганда, яисә артмаганда мөселман өммәтендәге кешеләр күбәюдә. Безнең дин тарафдарлары дөнья халкының чирегенә якынын (23 процент) тәшкил итә. Исламда, башкалар белән чагыштырганда, дингә ярты-йорты ышанучылар шактый аз. Динебез, көчен җуймастан, шактый уңай үзгәрешләр кичерде. Элекке заманнардагыча җыр-музыка, рәсем-сын сәнгатен тыю, инкарь итү бүген юк хисабында. Исламның радикаль агымнары да халыкта теләктәшлек тапмый. Дәүләт диннән аерылмаган ислам илләре дә бүген цивилизацияле юлда.

Диннәр бүген элекке чорларга караганда да ныграк кирәк. Ни генә әйтмә, бер-берсеннән аерылган җәһәттә дә алар барысы да гомумкешелек кыйммәтләре – әхлак, шәфкать, миһербанлык яклы бит.

## ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

**Уфада Башкортстанның Беренче Президенты Мортаза Рәхимов белән хушлаштылар.** Республиканың элеккеге җитәкчесен соңгы юлга озатырга Россия Президенты Владимир Путин да килде.

Билгеле булганча, Мортаза Рәхимов чәршәмбе көнне, озакка сузылган авырудан соң, 88 яшендә вафат булды. Матәм чарасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты. «Башкорт халкының бөек улын, күренекле дәүләт эшлеклесен озатабыз. Шушы катлаулы чорның символы булган кеше белән саубуллашабыз», – диде Башкортстан башлыгы Радий Хәбиров үз чыгышында.

Рөстәм Миңнеханов бөтен Татарстан халкы һәм шәхсән үз исеменнән тирән кайгы уртаклашу сүзләрен җиткерде.

– Башкортстанның Беренче Президентын соңгы юлга озатабыз. Ул безнең өчен якын кеше иде. Бу – бөтен ил өчен зур югалту. Мортаза Рәхимов Минтимер Шәймиев белән дус булды һәм бу безнең тыгыз элемтәләрдә дә чагылыш тапты, – диде Татарстан Президенты.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Мортаза Рәхимов үз халкы өчен бөтен көчен һәм белемен биргән. «Мин аңа һәрвакыт зур хөрмәт белән карадым. Мортаза Рәхимовның якты истәлеге безнең йөрәкләрдә сакланачак», – диде ул.

Минтимер Шәймиев тә Башкортстанның Беренче Президентына бәйле истәлекләре белән уртаклашты.

– Без Мортаза Гобәйдулла улы белән ярышып эшләдек, көнләштек тә, бәхәсләштек тә, әмма һәрвакыт уртак тел таба идек. Ә аның белән дә, минем белән дә уртак тел табу җиңел булмады, – диде ул.

Минтимер Шәймиев искәртеп үткәнчә, татарлар һәм башкортлар – Россия үсешенә зур сәяси һәм икътисадый өлеш керткән тугандаш халыклар. «Ул тарихта яхшы эз калдырды, – диде Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Мортаза Рәхимов турында. – Күп нәрсәгә иреште. Россия үсешенә сәяси яктан да, хуҗалык эшләрендә дә җитди өлеш кертте. Барысы да җиңел бирелмәде, үзгәртеп кору еллары да булды. Иң мөһиме, Татарстан һәм Башкортстан җитәкчелеге бу күркәм традицияләрне дәвам иттерүгә иреште һәм бу хәзер дә шулай».

# ТҮЛӘҮ НИГЕЗЛЕ БУЛСЫН

**Нәтиҗә**

**Ут янсын, су аксын, ә чүпне вакытында чыгарсыннар, дисәң, түләргә туры киләчәк. Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетының еллык коллегиясендә халык арасында аңлату эшләрен арттырырга киңәш иттеләр. Бәяләр кыйммәтләнсә дә, тормыш дәвам итә.**



Илдар Мөхәммәтҗанов

Чарада катнашкан Россия Монополияләргә каршы федераль хезмәт җитәкчесе урынбасары Виталий Королев республика тарифчыларының эшен югары бәяләде. Аңлашыла ки, коллегиядә быелтыр коммуналь хезмәтләргә тарифларның бер ел эчендә ике тапкыр артуы турында сүз берничә тапкыр күтәрелде. Виталий Королев халыкка барысын да бәйнә-бәйнә аңлатырга киңәш итте.

Бу айда декабрь өчен түләү кәгазьләрен алучылар, яңа бәяләрне күреп, аптырашта калды. Ут һәм су кесәгә суга! Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев тынычландырырга да ашыкты: моннан ары коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 2024 елның җәендә генә артачак. Шулай итеп, ел ярым дәвамында кыйммәтләнмәячәк. Бу мәсьәләдә халык белән даими эш алып барылуына да басым ясады ул. Узган ел, мәсәлән, Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетына килеп ирешкән мөрәҗәгатьләрнең 30 проценты диярлек коммуналь хезмәтләр өчен бәяләргә бәйле булган. Икенче урында – су мәсьәләсе (20 процент). Халык арасында ут белән тәэмин итү дә еш борчу уята (19 процент).

Александр Груничев әйтүенчә, халыкка күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясе аның сыйфатына туры килергә дә тиеш. «Мәсәлән, Бөгелмәдә яшәүчеләрнең күбесе өйдәге торбаларның бер караганда – җылы, икенче караганда суык булуыннан зарланды. Моңа бәйле кыенлыклар булуын җылылык белән тәэмин итүче оешма да раслады. Тик менә коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазендә бу берничек тә чагылыш тапмаган. Әлеге мәсьәлә контрольгә алынды. Халыкка килмәгән җылылык өчен акчаны кире кайтарачаклар», – диде Александр Груничев. Ул тагын бер кат шуны да искә төшерде: коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты начар, алар вакытында күрсәтелмәгән яки исәпләүләргә бәйле шикаятьләр булган очракта, иң элек коммуналь хезмәтләрне күрсәтүчегә, ә алардан тиешле җавап булмаса яки ул канәгатьләндермәсә, Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетына яки Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә субсидия дә каралган. Былтыр республикада яшәүче 72927 гаилә дәүләттән 1 миллион 70 мең сумлык ярдәм алган. Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, хезмәт ветераннары кебек ташламага ия булучыларга 4 миллион 340 мең сумлык субсидия түләнгән.

Тарифларны арттырмыйча да булмый. Коллегиядә чыгыш ясаган Питрәч районы башлыгы Илһам Кашапов әйтүенчә, соңгы ун елда районда яшәүчеләр саны ике тапкыр арткан. «Бүген Питрәчтә 62 мең кеше теркәлгән, яшәүчеләр саны исә тагын да күбрәк. Былтыр төзелеш планын 120 процентка үтәдек. Барлыгы 239 мең квадрат метр торакны кулланышка тапшырдык. Димәк, инженер челтәрләрен дә даими карап, төзәтеп торырга кирәк. Бу исә – чыгымнар дигән сүз. Районда, мәсәлән, чиста суга тариф 26 сум 24 тиен тәшкил итә. Хезмәт күрсәтүче оешмаларга бу ертыкларны ямарга гына җитә. Тиешле чара күрелмәсә, тагын 7–10 елдан торбалар тузачак», – дип сөйләде ул.

Халыкны борчыган тагын бер мәсьәлә: республикада торак йортларга кадәр бушлай газ тоташтыру программасының (догазификация) үтәлеше. Билгеле булганча, әлеге программа кысасында газны йортка кадәр китерәләр, ә аны өй эченә кертүне шәхси оешмалар ярдәмендә һәркем үзе хәл итә. Тик халык бу эшнең шактый кыйммәт булуыннан зарлана. Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетында да исәпләп караганнар. «Капкадан өйгә кадәр ара шартлы рәвештә 22 метр дип алсак, корыч, полиэтилен торбаларны, краннарны да исәпкә алып, газны плитәгә тоташтыру 35 мең сумга төшә», – ди Александр Груничев. Кәгазьдәге саннар белән чынбарлык арасындагы «упкын»ны тикшерергә вәгъдә иттеләр.

Алга таба сыек көнкүреш калдыкларын чыгару эшен дә җайга салмакчылар. Татарстан Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты җитәкчесе Александр Тыгин сүзләренә караганда, республика депутатларының бу мәсьәләгә бәйле тәкъдимен илнең 35 төбәгендә хуплаганнар инде. Сүз сыек көнкүреш калдыклары чыгаруга тариф булдыру, транспорт белән алып китүне тәэмин итү, чистарту һәм утильләштерү турында бара. Әлегә исә бу – шәхси йортта яшәүчеләрнең үз баш бәласе.

Кыйммәтле коммуналь түләү кәгазьләре «күләгә»сендә калган тагын бер яңалык – җәмәгать транспортында йөрүгә бәяләр арту турында да сүз булды. 10 гыйнвардан юл билеты өчен банк картасы яки транспорт картасы белән түләгәндә юл бәясе 4 сумга артты һәм 35 сумга җитте. Александр Груничев исә иртәгәге көн турында да уйлый башларга киңәш итте. Бигрәк тә, тимер юл һәм елга транспортына бәйле мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк. Тимерне кызуында сугып, коллегиядә катнашкан Татарстан Премьер-министры Александр Песошин Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына республиканың транспорт тармагын үстерү концепциясен төзергә кушты.

Эльвира ВӘЛИЕВА

# Ышаныч аклансын

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның журналистлар белән традицион очрашуында яңгыраган төп фикерләрнең берсе бу. Очрашу, елдагыча, 13 гыйнвар – Россия матбугаты көнендә узды.

Фикер алышу өчен урын елына туры китереп сайланган иде. 2023 ел республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителгәнгә күрә, бу юлы Татарстан журналистлары Казан халык сәнгате һөнәрчелеге техникумына җыелды. Парламент Рәисе белән очрашуга кадәр, төрле остаханәләрдә катнашып, яңа кәсепләр үзләштерү мөмкинлеге бар иде. Бәйрәм булгач, язу-сызу эшеннән бераз булса да ял итсеннәр, дигәннәр, ахры.

Шуннан соң журналистларны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев котлады.

Фәрит Мөхәммәтшин исә сүзен матбугат хезмәткәрләренә рәхмәт әйтүдән башлады.

– Безнең бүгенге очрашуыбыз матур бер традициягә әйләнде. Республика җитәкчелеге исеменнән сезне бәйрәмегез белән котлыйм һәм зур рәхмәтемне җиткерәм. Без шактый катлаулы чорда яшибез. Әмма горурланып шуны әйтә алам: Татарстан журналистикасы замананың катлаулы сынауларына бирешми, аларга лаеклы рәвештә җавап бирә, – диде ул. – Ветераннарыбызга аерым рәхмәт. Мин сезнең алда баш иям! Риман Гыйлемханов, Габделбәр Ризванов, Любовь Агеева, Мөнир Әһлиуллин, Александр Малов, Тәүфикъ Сәгыйтов, Фәрит Гобәев, Әгъзәм Фәйзрахманов, сез – яшь буын журналистларына безнең күркәм традицияләребезне тапшыручылар, Татарстан журналистикасының «алтын фонды»!

Парламент Рәисе бүгенге җәмгыятьтә журналистларга карата ышанычның югары дәрәҗәдә булуын искәртте.

– Сез бу ышанычны акларга тиеш. Дөньядагы соңгы вакыйгаларга бәйле рәвештә массакүләм мәгълүмат чараларының иҗтимагый-сәяси кырдагы роле тагын да артты. Шуның белән бер рәттән җиткерелә торган мәгълүмат өчен җаваплылык хисе дә артырга тиеш, – диде Мөхәммәтшин. – Мәгълүмати каршылык кискенләшкән чорда укучыга яңалык агымын «кичеп» чыгарга ярдәм итү мөһим. Бу бурычны сездән кала берәү дә башкара алмый.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренчә, журналистларның тагын бер мөһим бурычы – традицион кыйммәтләр турында күбрәк сөйләү. Ул әлеге мәсьәләнең узган елгы Президент Юлламасында да күтәрелүен искәртте.

Шуннан соң ул басма матбугат вәкилләрен борчыган мәсьәләгә тукталды. Икенче яртыеллыкта газета-журналлар гомуми тиражының сигез процентка диярлек кимүе турында әйтте. «Шулай да, Татарстанның басма матбугаты илдә иң көчлеләр рәтендә кала бирә», – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

# САКЛАНУ АРТЫК ТҮГЕЛ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстандагы хәлләргә килгәндә, республикада яңа елның беренче атнасында грипп һәм ОРВИ белән чирләүчеләр саны 12672гә җиткән. Узган атналар белән чагыштырганда, бу – 20,9 процентка кимрәк сан.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, чирләр арасында грипп өстенлек итә. Гыйнвар азагы – февраль башында авыру очраклары тагын да артыр дигән фараз да бар.

Онытыла башлаган коронавирус та үзе турында кабат искә төшерде. «Кракен» дигән штаммы турында кисәтә белгечләр. Анысын да, куркыныч, диләр. Казан федераль университетының Фундаменталь медицина һәм биология институтының прецизион һәм регенератив медицина фәнни-клиник үзәге директоры Альберт Ризванов бу җәһәттән аңлатма бирде.

– «Кракен» – «омикрон»ның чираттагы бер төре, ул аның ике штаммы кушылуыннан барлыкка килгән. Ул коронавирус инфекциясенең иң йогышлы төре булып санала. Баштарак коронавирусны йогышлылыгы буенча грипп һәм кызамык белән чагыштырган булсалар, хәзер инфекция күрсәткече барлык башка авырулардан да өстен чыкты, – ди белгеч.

Альберт Ризванов вакцинация һәм ревакцинация мәсьәләсенә дә җитди карарга куша. «Спутник V» – саклану өчен бер дигәннәрдән.

# ЧҮПНЕ БУРАН СЕБЕРМИ

**Чүп мәсьәләсенең ел дәвамында тынып торганы юк. Юллары кардан чистартылып, вакытында тәртипкә китерелеп торган авыллар моның авырлыгын сизми дә. Шул ук вакытта буранлап тору, техника булмау сәбәпле, кайбер авылларга чүп җыючылар барып җитә алмый. Андыйларга нишләргә?**



vk.com

Зур Кукмара авылында 2500 кеше яши. Кешесе күп булган җирдә чүбе дә күп була бит инде дип, аларның да хәлен белешәсе иттек. Биредә чүпне ике атнага бер тапкыр җыялар, тик юллар булмау сәбәпле, берничә хуҗалыкка кадәр уза алмыйлар икән.

– Авылның ике башында да яңа йортлар бар. Чүп җыючылар язын-көзен, кышын менә шуларга кадәр кереп җитә алмый. Чөнки анда юл юк, – дип аңлатты авыл советы башлыгы Ришат Хәнәфиев. – Әлеге участокларда яшәүчеләр каты көнкүреш калдыкларын үзәк урамга үзләре алып чыгарга мәҗбүр. Яки үзләре машиналарына куеп алып китеп ташлый.

Кышын бит әле юлларын да карап, чистартып торырга кирәк. Суыгы да, бураны да була, тракторы да ватылмый тормый.

– Бүген һава торышы тыныч, буран юк, тик барыбер кайбер урамнарга кереп булмый. Чөнки карны җил себереп тора, керсәң, чыгып булмаска мөмкин. Шуңа күрә кышын юллар – иң күп игътибар сорый торган тармак. Чүпкә контейнер куйдыру буенча да тәкъдимнәр булган иде, тик мин аны кирәксенмим. Мәшәкате генә артачак. Авылны чүп оясы ясауга каршы мин, – диде Ришат Хәнәфиев.

Моннан тыш, чүпне атна саен җыйсалар да яхшы булыр иде, ди авыл халкы. Тик шул ук вакытта бәясе күтәрелүне барлык кеше дә аңлап бетермәскә мөмкин.

– Агач ботаклары, бәрәңге сабаклары ише әйберләрне җыймый башлаулары да авыл өчен начар булды. Элек бу эшне авыл советы башкара иде. Хәзер кемдер яндыра, кемдер яр кырыена илтеп түгә. Агач ботагына чүпнең башкасы да ияреп килә бит инде, – диде ул.

Көзен Әгерҗе районының Яңа Бәзәкә авылында юллар начар булу сәбәпле, машиналарның ни керә, ни чыга алмый азаплануын язган идек. Кышын чүп алып китү мәсьәләсен дә белештек. Шөкер, кышын авылга керү-чыгу белән проблемалар юк икән. Карны вакытында эттереп, көрәп торалар. Чүп җыючы машина да, ике атнага бер тапкыр килеп, халыкның капчык белән чыгарып куйган чүпләрен алып китә.

– Сукбай этләр күп булган авылларга гына авыррак. Анда чүп җыючыларга хайваннар туздырган пакетларны, калдыкларны үзләренә җыярга туры килә. Бездә андый авырлык юк, – диде Фирдәвес Уразманов.

Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында да халыктан чүп җыю яхшы оештырылган. Биредә чүпне һәр шимбә көнне җыеп алалар.

– Юллар көн саен чистартылып, кардан ачылып тора. Проблемалар булганы юк. Һәр атнаның шимбәсендә килеп җыялар. Контейнерлар кую турында фикер алышулар булган иде, без һәркем көнендә капчыклап чыгарса яхшырак булыр, дигән нәтиҗәгә килдек, – диде Алия Шәрипова.

Күпчелек авыл халкы чүпләрен капчыкка салып чыгарса, контейнерлар куйдырган авыллар да бар. Әйтик, Әлки районының Карга авылында нәкъ менә шулай эшлиләр. Авыл уртача зурлыкта. Бәлки шуңа күрәдер, чүпне атнага бер тапкыр гына алып китсәләр дә, авылда теләсә кайда чәчелеп яткан чүп юк, ди биредә яшәүчеләр.

– Өч ел элек чүп чыгарыр өчен авылга унсигез евроконтейнер урнаштырдык. Тугыз урамда икешәр контейнер тора. Аларны үзара салым акчасына алган идек, мәйданчыкларын да шул хисаптан ясаттык. Мин 32 ел авыл советында эшлим. Шул еллар эчендә чүп мәсьәләсендә иң дөрес карар шушы булгандыр, дип саныйм. Чөнки өч елда авыл чүпкә баткан булыр иде инде. Аңа кадәр бөтен калдык-постык авыл читенә, чокыр-чакырларга чыга иде. Бер атна эчендә контейнер тулып, чүп-чары читкә таралып ятканы юк, – диде авыл советы башлыгы Рамил Минһаҗев.

Үзләре авылда яшәмәсәләр, чүп чыгармасалар да, йортта теркәлгән кешеләрдән акча түләттерү проблемасы турында да әледән-әле ишетеп торырга туры килә. Үлгән кешеләр исеменә түләү кәгазьләре килгән очраклар еш була икән. Аларын да тиешле органнарга хәбәр итеп, вакытында хәл итеп барырга кирәклеген әйттеләр.

– Үзләре читтә яшәсәләр дә, авылда теркәлгән кешеләргә чүп өчен түләү килә. Бик күпләргә кагыла бу мәсьәлә. Безгә шактый мәшәкать тудыра торган хәл. Андый кешеләр ике җирдә чүп өчен түләргә тиеш булып чыга. Мәсәлән, буш йортта теркәлгән кешенең барлык гаилә әгъзаларына килгән очраклар да булды. Андыйлар 18–20шәр мең түләргә тиеш булды. Хатлар яза-яза, көч-хәл белән бер кешегә калдырттык, – диде Рамил Минһаҗев.

Зөһрә САДЫЙКОВА